**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен кызыксындыру системасын камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында» 2015 елның 19 ноябрендәге ПУ-1111 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 18 мартындагы ПУ-172 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми порталында» сүзләрен «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасының «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайтында (алга таба – «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайты)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта «тәкъдим ителгәннәр арасыннан иң күбе унбиш дәүләт хезмәткәре кертелә» сүзләрен «тәкъдим ителгән дәүләт хезмәткәрләре кертелә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 пунктта «Электрон мактау тактасына кертү өчен дәүләт хезмәткәрләрен сайлап алу» сүзләрен «Электрон мактау тактасын формалаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

г) 8 пунктта:

беренче абзацта «10» санын «20» санына алмаштырырга;

икенче абзацка «бәйсез экспертларны, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте ветераннарын, Департамент вәкилләрен җәлеп итеп» сүзләрен өстәргә;

д) 11 пункттагы «25 февраль» сүзләрен «1 март» сүзләренә алмаштырырга;

е) 12 пунктта:

беренче абзацта «әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән чикләрдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

ж) 13 пунктта «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми порталында» сүзләрен «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайтында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 02 сентябрь
№ ПУ-615